СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**7 ноябрь 2023 ел** Болгар ш. **№ 33-4**

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2023 елның 05 июнендәге 30-4 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 05 июнендәге «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 30-4 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. «Спас муниципаль районында муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары " ТР Спас муниципаль районының муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта түбәндәге эчтәлектәге 3 нче пункт белән тулыландырырга:

«3. Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 статьясының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, формаларга, срокларга һәм вакытлычалыкка ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.»

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (//http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар аның басылып чыгу датасыннан үз көченә керә.

Спас муниципаль районы Башлыгы,
Советы Рәисе Ф. В. Мөхәммәтов